**Республика Татарстан**
**Совет Верхнешипкинского сельского поселения Заинского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлеге**

Ул. Молодежная , д. 1, с. Верхние Шипки, Заинский район, 423518

Яшьләр урамы, 1нче йорт, Югары Шепкә авылы, Зәй районы, 423518

Телефон, факс 69-2-77. Электронный адрес: Vship.Zai@tatar.ru, сайт: www.zainsk.tatarstan.ru/tat/verhneshipkinskoe.htm

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25.03.2019 ел** **№ 1**

**«Аерым категориядәге затларның вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәве белән бәйле рәвештә бүләк алуы турында хәбәр итү тәртибе, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 11 мартындагы 01 номерлы Югары Шепкә авыл жирлеге башлыгы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл жирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. «Аерым категориядәге затларның вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәве белән бәйле рәвештә бүләк алуы турында хәбәр итү тәртибе, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 11 мартындагы 01 номерлы Югары Шепкә авыл жирлеге башлыгы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

1.1. 2 өлешнең 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукына ия» сүзләрен «комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия» сүзләренә алмаштырырга.

2. Карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы А.Х.Ишматов**